| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**27.11.2020** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 2281** |

Зеленодольск муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 17 апрелендәге 678 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләрен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүгә бәйле исемле бердәм электрон социаль йөртү билетлары буенча йөртүдән алынмаган керемнәрне каплау максатларында, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан оешмаларга субсидияләр бирү турындагы гаризаларны карау буенча комиссия составына үзгәрешләр кертү турында

2008 елның 19 декабрендәге «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 123-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетында кадрлар үзгәрешләренә бәйле рәвештә,Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 17 апрелендәге 678 номерлы карары белән расланган, әлеге карарның кушымтасына бирелгән, яңа редакциядә төзелгән Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләрен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүгә бәйле исемле бердәм электрон социаль йөртү билетлары буенча йөртүдән алынмаган керемнәрне каплау максатларында, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан оешмаларга субсидияләр бирү турындагы гаризаларны карау буенча комиссия составын расларга.

2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 17 апрелендәге «Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләрен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүгә бәйле исемле бердәм электрон социаль йөртү билетлары буенча йөртүдән алынмаган керемнәрне каплау максатларында, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан оешмаларга субсидияләр бирү турындагы гаризаларны карау буенча комиссия төзү турында» 678 номерлы карарының 1 нче кушымтасы үз көчен югалткан дип санарга.

3. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (.http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) интернет челтәрендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе И. Р. Ганиев

Кушымта
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты карарыны
27.11.2020 №2281

**Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләрен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүгә бәйле исемле бердәм электрон социаль йөртү билетлары буенча йөртүдән алынмаган керемнәрне каплау максатларында, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан оешмаларга субсидияләр бирү турындагы гаризаларны карау буенча комиссия составы**

| № т/б | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Вазыйфасы |
|---|---|---|
| 1. | Ганиев Ильяс Рәсим улы | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе-комиссия Рәисе |
| Комиссия әгъзалары: | | |
| 2 | Ибраһимов Дамир Рәшит улы | «Төзелеш һәм инфраструктура үсеше департаменты» МБУ җитәкчесе урынбасары-комиссия секретаре |
| 3 | Нурмөхәмәтов Әмир Җәмил улы | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары вазыйфаларын башкаручы |
| 4 | Стерякова Анастасия Сергеевна | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының социаль-икътисадый фаразлау һәм үсеш бүлеге начальнигы |
| 5 | Ламбина Татьяна Михайловна | «ЗМР Финанс-бюджет палатасы» МУ җитәкчесе урынбасары |